**“АРЧА 1 НЧЕ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ”**
**муниципаль мәктәпкәчә белеем учреждениесе**

**Әти-әниләр һәм балалар өчен татарча газета**

# Чишмә башы

*Кадерле дуслар!*
*Яңа ел бәйрәме мөбәрак булсын! Алдагы өр-яңа ел бары бәхет-куанычлар гына алып килсен. Туасы таңнар тыныч булсын. Гомер юлларыбыз һәрчак шатлык белән тулып торсын . Кызыклы очрашулар, бәхетле мизгелләр күп булсын! Барлык өметләрегез дә аклансын, ел буена күтәренке кәеф, сәламәтлек, гаилә иминлеге озата барсын сезне. Ил-көнебез тыныч, барыр юлларыбыз киң, туар таңнарыбыз имин булсын.*
*Яңа еллар мөбарәк булсын!*

*Иң изге теләкләр белән*
*Арча 1 нче балалар бакчасы мөдире*
*Шакирова Алсу Фаридовна*

**Бүгенге чыгарылышта:**


- Яңа ел котлаулары
- «Ел тәрбиячесе –2025» бәйгесе нәтиҗәләре
- Яңа ел иртәләре
- «Яңа ел фантазиясе» бәйгесе
- «Солдатка бүләк» акциясе

## «Ел тәрбиячесе 2025» республика бәйгесенең муниципаль этабы



Безнең балалар бакчасында «Ел тәрбиячесе 2025»республика конкурсының муниципаль этабы узды. Районыбызның иң көчле сигез балалар бакчасы тәрбиячесе үзләренең осталыкларын күрсәттеләр. Безнең балалар бакчасын 1нче зурлар торкеме тәрбиячесе Хисмәтуллина Алинә Әхтәм кызы тәкъдим итте. Хисләр дулкыны кичереп, кыйммәтле тәҗрибә туплап, Алинә Әхтәм кызы диплом һәм бүләкләр белән бүләкләнде! Котлыйбыз һәм Сезнең белән горурланабыз!

## Бакчабызда Яңа ел бәйрәме иртәләре гөрләп узды



**Бәйрәм бүген –Яңа ел,**
**Бөтен җиргә кар кунган.**
**Яңа елны каршылап,**
**Кунаклар да җыелган.**
**Нинди матур безнең чыршы,**
**Җем-җем килеп яна ул.**
**Башлыйбыз чыршы бәйрәмен,**
**Котлы булсын Яңа ел!**

Яңа ел - балалар өчен дә, өлкәннәр өчен дә шатлыклы әкият. Бу көннәрдә Арчаның 1 нче номерлы балалар бакчасында, бәйрәмчә бизәлгән зал балаларны күңелле Яңа ел музыкасы һәм якты утлар белән каршы алды. Безнең балалар шундый матур, шундый гаҗәеп, шатлыклы, малайлар пингвиннарга, кызлар феяга әверелделәр. Балалар матур чыршы янында Кыш бабай һәм Кар кызы белән күңел ачтылар. Алар әйлән-бәйлән йөрделәр, шигырьләр сөйләделәр, уеннар уйнадылар, биеделәр. Балалар Кар кызына бәйрәм чыршысында ут кабызырга ярдәм иттеләр. Әлбәттә инде безгә Кыш бабай бүләкләр белән килде. Бәйрәм балаларга бары тик уңай эмоцияләр генә китерде һәм Яңа елны якынайтты.

## Шәһәр чыршысын бизибез!

**Балаларыбыз «Яңа ел фантазиясе» дип исемләнгән район бәйгесендә катнашты**





## Бакчабызда “Солдатка бүләк» акциясе булып узды




